## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“29” ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 29 ноябрендә «Сез 2021 елда Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 900 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Түбән Көек авылы территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.
2. Урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу.
3. Юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру.
4. Түбән Көек авылы зиратын коймалап алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү.
5. Түбән Көек авылында урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, ташу, аларны җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү)”
6. Эре мөгезле терлек өчен электрон көтүче сатып алу.

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 211 (ике йөз унбер) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 147 (бер йөз кырык җиде) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 147 (бер йөз кырык җиде) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2021 елда Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 900 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Түбән Көек авылы территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.
2. Урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу.

3. Юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру.

4. Түбән Көек авылы зиратын коймалап алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү.

5. Түбән Көек авылында урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, ташу, аларны җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү)”

6. Электрон көтүче сатып алу мәсьәләләрен кабул итәргә.

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләләрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.